**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д.24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел.: (8-85592) 3-16-63, 6-12-21
факс: (8-85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Актүбә бистәсе башкарма комитеты**

Губкина урамы, 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел.: (8-85592) 3-16-63, 6-12-21
факс: (8-85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 09 2019 ел № 108

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 24.03.2004 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ "ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА АКТЮБИНСКИЙ" АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына кушымта №1
«03» 09 2019 ел № 108

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә » муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 31 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түли.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 2 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,

в) күп балалы гаиләләр,

түләү күләме җирле референдум (гражданнар җыенында) карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәрнамә) бланкы, җирлек сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән, гражданнарга җиткерелә: http://aznakayevo.tatarstan.ru шулай ук почта элемтәсе аша имза яисә юллама тапшыру юлы белән (әлеге Тәртипкә кушымта).

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнардан кергән үзара салым акчалары Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) башкаруга, Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бирелә. https://uslugi.tatarstan.ru/

8. Түләү фактын раслап, керемле касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарныц үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге торак пукнктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында

ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.О.
_______________________________________________________________

Адрес:
_______________________________________________________
____________________________________________________нигезендә

Сезгә ________ кадәр үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

_____________ сум

реквизитлар:_____________________________________________

алучы банкы БИК __________________________________

Сч. № ______________________________

Сч. № ____________________________________

ИНН _____________________________________

КПП _____________________________________

КБК ______________ ОКАТО ________________

Түләүнең билгеләмәсе
_______________________________________________________________

Җитәкче________________ ____________________________________

М.П. (имза) (расшифровка)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Хәбәрнамә (Уведомление) № _______________

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында
____________________

*(муниципаль берәмлек исеме)*

______________ сум

Түләүченең Ф.И.О.
__________________________________________________

Адресы:
_______________________________________________________________

«__» _____________ 20__ г. ______________________________

(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок) «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*